**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.12.2024 №776

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән балаларны түләүсез кайнар ризык белән туклandыруны тәэмин итү турында» 2022 елның 09 декабрендәге 1339 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2023 елның 11 декабрендәге 2173 номерлыкарар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм буенча өстәмә чаралар турында» 2022 елның 14 декабрендәге 1122 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кама Тамагы районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән балаларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү турында»

2022елның 9 декабрендәге1339  номерлы карарына (2023 елның 11 декабрендәге 2173 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.1. Махсус хәрби операциядә катнашучы, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында оешкан «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүчеләргә, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның гаиләләреннән булган (гаилә әгъзаларына) Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә башлангыч, төп гомуми һәм урта гомуми белем алучы балаларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итәргә.:

- көнгә 32.4 сум - ата-ана түләве;
- 23,00 сум - озынайтылган көн төркеменең ата-аналар түләве;
- 9,60 сум - республика субсидиясе».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Х. Хәбибулловага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Баржанов